МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

19 август 2026 ел

№ М 436

Шәһәр Хакименең 2018 елның 9 июлендәге М 299 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең аерым указлары үз көчләрен югалтуын тану турында» 2026 елның 9 апрелендәге 278 номерлы Указы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең 2018 елның 9 июлендәге М 299 номерлы Карары белән (Шәһәр Хакименең 2021 елның 27 декаберендәге М 529 номерлы, 2024 елның 2 маендагы М 234 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Комиссия шәһәр Хакимияте карары белән төзелә. Күрсәтелгән карар белән комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре билгеләнә һәм комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

2) 7 пунктның 1 пунктчасына «аның тарафыннан вәкаләтләнгән зат» сүзләреннән соң «(комиссия рәисе), муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче зат (комиссия рәисе урынбасары);» сүзләрен өстәргә;

3) 7 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) җирле үзидарә органының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны

профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе җитәкчесе яисә җирле үзидарә органының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы кадрлар хезмәте рәсми заты (комиссия секретаре), җирле үзидарә органының юридик (хокук) бүлекчәсеннән, башка бүлекчәләреннән аның җитәкчесе тарафыннан билгеләнә торган муниципаль хезмәткәрләр;»;

4) 9 пунктның икенче җөмләсен төшереп калдырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев